ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.02.2019 № 188

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының
2018 елның 19 мартындагы 185 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 19 мартындагы 185 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планы өлешендә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Ресурс белән тәэмин итү буенча IV бүлектә:

- «3 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2018 елда Кыска вакытлы план чараларын финанслауның гомуми күләме:

53315887,78 сум, шул исәптән:

Фондтан- 0,00 сум;

Татарстан Республикасы бюджетыннан – 12446168,00 сум;

җирле бюджеттан – 11 288 000,00 сум;

ТМШ, ТК, ТТК әгъзалары яисә башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы яки күпфатирлы йортта торак хуҗалары кооперативы – 29581719,78 сум»

- «2018 елда күп фатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрүгә финанс чараларының ихтыяҗлары күләмен киләсе редакциядә бәян итәргә:

Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь төзекләндерү буенча хезмәтләр яки эшләрнең исемлеге	Финанслау ихтыяҗы, сум.
Түбәне төзекләндерү	21534607,30
Йорт эчендәге инженерлык системаларын төзекләндерү, шул исәптән:	19982939,83
Электр белән тәэмин итү	2945487,49
Җылылык белән тәэмин итү	12897133,77
Су белән тәэмин итү	1538903,03
Суны агызып җибәрү	2601415,54
Фасадларны җылыту һәм төзекләндерү	9521024,75
Күпфатирлы йортларда подъездларны төзекләндерү	104881,22
Проект документациясен эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү	1 408 080,94
Төзелеш контроле уздыру	567 618,54
Техник паспортларны ясау	196 735,20
БАРЛЫГЫ	53315887,78

2. “Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 мартындагы 185 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 ел, 22 ноябрь, 965 нче карары әлеге карар теркәлгән көннән үз көчен югалткан дип санарга.

Җитәкче Л.Н. Маняпов